РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Исполнительный комитет
Шингальчинского сельского поселения
Нижнекамского муниципального района

423554, Нижнекамский район,
с. Шингальчи, ул.Школьная, 6

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районының
Шәңгәлче авыл җирлеге
Башкарма комитеты

423554, Түбән Кама районы,
Шәңгәлче авылы, Мәктәп урамы, 6

тел./факс (8555) 43-04-50, электронный адрес: Shingalchinskoe.Sp@tatar.ru, сайт: www. shingalchinskoe-sp.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 02.07.2019 г. №38

Татарстан РеспубликасыТүбән Кама муниципаль районы Шәңгәлче авыл җирлеге башкарма комитетының 2016 елның 27 гыйнварындагы 5 номерлы карары белән расланган күчемсез милек объектларына адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертүтурында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә карарбирәм:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Шәңгәлче авыл җирлеге башкарма комитетының 2016 елның 27 гыйнварындагы 5 номерлы карары белән расланган күчемсез милек объектларына адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган теркәлгән үзгәрешләрне расларга.
2. Әлеге карарны җирлек Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны җирлекнең Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Р.Х. Сәлимов

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Шәңгәлче авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең
2019 елның «02 » Июльдә
38 номерлы карары белән расланган
кушымта

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Шәңгәлче авыл җирлеге башкарма комитетының 2016 елның 27 гыйнварындагы 5 номерлы карары белән расланган күчемсез милек объектларына адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1. 1.2.пунктның тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Коммерцияле булмаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәте әгъзалары исеменнән мондый ширкәт әгъзаларының гомуми җыелышы карары белән кабул ителгән мондый гаризаны тапшырырга вәкаләтле ширкәт вәкиле гариза белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.»

2. Стандартка таләпләр эчтәлеге баганасының 2.5. пункты «г» пунктчасы 2 абзацынтөшереп калдырырга.

3. Стандартка таләпләр эчтәлеге баганасының 2.8. пунктынтүбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Нигезләр каралмаган.»

4. «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр исеме» баганасының 2.14. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләрне көтү һәм кабул итү урынына, шул исәптән әлеге объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итүгә инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә, мондый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерүгә таләпләр.».

5. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.14. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмати стендлар беләнҗиһазландырылган биналарда һәм йортларда башкарыла. Инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү мөмкинлеге тәэмин ителә (бинага уңайлы керү-чыгу һәм алар чикләрендә хәрәкәт итү). Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.».

6. «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр исеме» баганасының 2.15. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.15. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүченең вазыйфаи затлар белән үзара хезмәттәшлеге саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең ераклаштырылган эш урыннарындамуниципаль хезмәт күрсәтү алу мөмкинлеге, муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмати-коммуникацион технологияләр кулланып.».

7. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.15. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуы күрсәткечләре булып тора:

җәмәгать транспортының һәркем файдалана алырлык зонасында урнашкан бина;

кирәкле сандагы белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итеүә торган биналар булу;

мәгълүмати стендларда, «Интернет» челтәрендәге мәгълүмат ресурсларында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;

башка затлар белән беррәттән хезмәт күрсәтү алуга комачаулаучы киртәләрне җиңеп чыгарга инвалидларга ярдәм күрсәтү.

Муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләрбулмау белән характерлана:

мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү һәм бирү чиратлары;

муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозу;

муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять;

муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә карата әдәпсез, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр.».

8. 3.1. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гариза гариза бирүче (гариза бирүче вәкиле) тарафыннан авыл җирлеге башкарма комитетына кәгазьдә почта аша кушып салынган әйберләр исемлеге һәм тапшыру турында хәбәрнамә белән җибәрелә яки гариза бирүче тарафыннан шәхсән тапшырыла.»

9. 3.3.2. пунктының 7 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Регламентның 2.5. пунктында күрсәтелгән гариза һәм документлар гариза бирүче (гариза бирүче вәкиле) тарафыннан авыл җирлеге башкарма комитетына шәхсән тапшырыла икән, мондый орган гариза бирүчегә яки аның вәкиленә документларның исемлеген һәм алу датасын күрсәтеп, документлар алуда расписка бирә. Вәкаләтле орган мондый документларны алган көнне гариза бирүчегә (гариза бирүче вәкиленә) расписка бирелә.

Регламентның 2.5 пунктында гариза һәм документлар вәкаләтле органга почта аша җибәрелгән очракта, мондый гариза һәм документлар алу турында расписка вәкаләтле орган тарафыннан гаризада күрсәтелгән почта адресы буенча вәкаләтле орган документлар кабул иткән көннән соң килгәнэш көне дәвамында җибәрелә.»

10.3.3.2 пунктының 10абзацын төшереп калдырырга.

11.5.1. пунктының 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) гариза бирүчедән тапшыру яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлары белән аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру каралмаган документлар яки мәгълүмат яисә эшне гамәлгә ашыруны таләп итү.

12. 5.1. пунктын 8), 9), 10) пунктчалар белән тулыландырырга.

«8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү вакытын яки тәртибен бозу;

9) әгәр туктату нигезләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган булса, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәрененңкарарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү шул очракта мөмкин, әгәркарарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына)шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федеральзаконның 16 статьясы 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү вазыйфасы йөкләнгән булса.

10) гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәткәндә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартканда аларның булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документлар яисә мәгълүмат таләп итү, яисә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш муниципаль хезмәт күрсәтү. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәрененңкарарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына)судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирүшул очракта мөмкин, әгәр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү вазыйфасы йөкләнгән булса.».

13. 5.8. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиешле дип танылган очракта, гариза бирүчегә, муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган житешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында, җирлек башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла торган эшләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында мөрәҗәгать итүчегә башкарылырга тиешле алга таба эшләр турында мәгълүмат күрсәтелә.»;

14. 5 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 5.9, 5.10 пунктларын өстәргә:

«5.9. Шикаятьканәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарка шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.10. Шикаятьне карау барышында яисә карап тикшерү нәтиҗәләре буенча

административ хокук бозу составы билгеләре яки җинаять билгеләре ачыкланганда, шикаять карау буенча вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына юллый.».